# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I бүлек), № 12 (IV бүлек); 2007, № 1 (I өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яисә җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертү (аннан төшереп калдыру) турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы тарафыннан карар кабул итү тәртибен билгеләү;";

2) 15 статьяның 10 пунктчасында "федераль," сүзен төшереп калдырырга;

3) 20 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) $24^1$ статьяның 3 пунктында:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мәдәни мирас объектына милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алганда, милекче шушы объектка милекчелек хокукына чикләүләр (йөкләүләр) булып торучы һәм мәдәни мирас объекты милекчесенең саклау йөкләмәсендә мәдәни мирас объектын тоту, аны саклап калу буенча (реставрацияләү, төзекләндерү һәм бүтән эшләрне башкару тәртибенә һәм срокларына карата таләпләрне дә кертеп) күрсәтелә торган йөкләмәләрне, гражданнарның аннан файдалана алу шартларына

таләпләрне, аның саклanышын тәэмин итә торган башка таләпләрне үз өстенә ала.";

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Мәдәни мирас объектларын дәүләт милкеннән яисә муниципаль милектән читләштергәндә, яңа милекче мәдәни мирас объектын тоту, аны саклап калу буенча (реставрацияләү, төзекләндерү һәм бүтән эшләрне башкару тәртибенә һәм срокларына карата таләпләрне дә кертеп), гражданнарның аннан файдалана алу шартларына таләпләрне, аның саклanышын тәэмин итә торган, шушы объектка милекчелек хокукына чикләүләр (йөкләүләр) булып торучы һәм мәдәни мирас объекты милекчесенең саклау йөкләмәсендә федераль законнар нигезендә күрсәтелә торган башка таләпләрне үтәү буенча йөкләмәләрне үз өстенә ала.";

5) $24^2$ статьяның 2 пунктында "объектның сакланып калуын тәэмин итәрлек бүтән таләпләр" сүзләрен "шушы объектның саклanышын тәэмин итә торган һәм шушы объекттан файдалану хокукына чикләүләр (йөкләүләр) булып торучы таләпләр" сүзләренә алмаштырырга;

6) 28 статьяда:

а) 2 пунктта "Дәүләт контроле объектлары" сүзләреннән соң ", исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш," сүзләрен өстәргә;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы түбәндәгеләргә дәүләт контролен гамәлгә ашыра:

1) мәдәни мирас объектларын саклап калуга, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга;

2) мәдәни мирас объектларының торышына (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш);

3) төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын, ачыкланган мәдәни мирас объектларын хосусыйлаштырганда саклау йөкләмәләре, шулай ук төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары милекчеләренең һәм шушы объектлардан файдаланучыларның саклау йөкләмәләре шартларының үтәлешенә;

4) мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру вәкаләтләренең Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан тулы һәм сыйфатлы итеп гамәлгә ашырылуына.";

в) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 29 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"29 статья. **Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә дәүләт контроле**

Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә дәүләт контроле мәдәни

мирас объектларын саклау буенча федераль орган һәм Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә федераль законнар һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.";

8) 30 статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"30 статья. **Мәдәни мирас объекты территориясендә һәм мәдәни мирас объектын саклау зоналарында мәдәни мирас объектларының сакланышын, җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне тәэмин итү чараларын проектлауга һәм башкаруга контроль**";

9) 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"31 статья. **Мәдәни мирас объектларының торышына дәүләт контроле**

Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органы Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының һәм ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышына контрольне гамәлгә ашыра һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәй дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) саклап калу буенча еллык һәм озак сроклы программалар эшләү максатларында биш елга бер мәртәбә шушы мәдәни мирас объектларының торышын тикшерүне һәм фотога төшерүне башкара.";

10) 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"32 статья. **Тарихи җирлекне саклау предметы**

Тарихи җирлектә шәһәр барлыкка китерә торган тарихи кыйммәткә ия барлык объектлар: планлаштыру, төзелмә, композиция, табигый ландшафт, археологик катлам, төрле (ирекле, төзелгән, яшелләндерелгән) шәһәр киңлекләре арасындагы бәйләнеш, күләм-киңлек структурасы, фрагментлардан һәм хәрабәләрдән гыйбарәт шәһәр төзелеше мирасы, масштабы, күләме, структурасы, стиле, материаллары, төсе һәм декоратив элементлары белән берләшкән биналарның һәм корылмаларның рәвеше һәм тышкы күренеше, табигать һәм кеше тарафыннан барлыкка китерелгән тирәлекнең бәйләнеше, тарихи җирлекнең үсеш барышында барлыкка килгән төрле функцияләре, шулай ук башка кыйммәтле объектлар дәүләт саклавында булалар.";

11) 40 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"40 статья. **Юкка чыккан мәдәни мирас объектларын торгызу**

1. Юкка чыккан мәдәни мирас объектларын торгызу юкка чыккан объектлар аерым тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булганда һәм торгызу өчен кирәкле фәнни

белешмәләр җитәрлек булганда гына махсус очракларда реставрацияләү ысуллары белән гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектларын торгызу федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары, шулай ук бюджеттан тыш чаралар исәбеннән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы бюджеты чаралары, шулай ук бюджеттан тыш чаралар исәбеннән торгызу турындагы карар Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органының тарихи-мәдәни экспертиза бәяләмәсенә нигезләнгән тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

4. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын торгызу турындагы карар җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алып, ә дини билгеләнештәге ядкарьне яисә ансамбльне торгызганда шулай ук дини оешмаларның фикерен исәпкә алып кабул ителә.

5. Юкка чыккан мәдәни мирас объектларын торгызу турындагы карарларны кабул итү төбәк (республика) реестры белешмәләре һәм Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни таяныч планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Яңадан торгызылган мәдәни мирас объекты федераль законнарда һәм әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә, аны торгызган мизгелдән кимендә кырык ел узгач, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мәдәни мирас объектларына кертелергә мөмкин.

7. Татарстан Республикасында юкка чыккан мәдәни мирас объектын федераль бюджет чаралары исәбеннән торгызу турындагы карар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.";

12) 45 статьяның 1, 2 һәм 4 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 56-ТРЗ